# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Казаклар авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 21 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 33-ФЗ Федераль “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылы торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәр бала тәрбияләүче ялгыз аналар, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срочная хәрби хезмәткә чакырылган затлар; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларны һәм аларның гаилә әгъзалары керми.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы карап тоту , смета документациясен төзү);

2) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы сугышчылары истәлегенә мемориал төзү һәм урнаштыру; проект-смета документациясе.

3. Элеге карарны Олыяз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче

Олыяз авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Маликов

ОГРН 1021607754651 ИНН 1623001879